КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 27 февраль г.Казань № 132

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Каюм Насыйри исемендәге премия турында» 1995 ел, 19 июнь, 396 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Каюм Насыйри исемендәге премия турында» 1995 ел, 19 июнь, 396 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 30 декабрь, 1141 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның исемендә «Насыри» сүзен «Насыйри» сүзенә алмаштырырга;

карарның преамбуласын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Милли мәгариф системасын камилләштерү һәм алга таба үстерү, бөек татар галиме-мәгърифәтче Каюм Насыйриның педагогик мирасын тирән өйрәнү һәм киң куллану, шулай ук педагогик коллективларны һәм мәгариф хезмәткәрләрен матди һәм рухи яктан кызыксындыру ролен көчәйтү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

карарның текстында «Татарстан Республикасының Мәгариф министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Түбәндәгеләрне расларга (карарга теркәләләр):

Каюм Насыйри исемендәге премия турында нигезләмә;

Каюм Насыйри исемендәге премия бирү комиссиясе турында нигезләмә;

Каюм Насыйри исемендәге премия лауреаты дипломы бланкы үрнәге;

Каюм Насыйри исемендәге премиягә бүләкләү кәгазьләре үрнәкләре.»;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына ел саен Каюм Насыйри исемендәге ике премия бирү хокукы бирелә, дип билгеләргә, шул исәптән:

педагогик коллективларга – 70 мең сум күләмендә;

Татарстан Республикасының мәктәпкәчә, өстәмә, гомуми урта, башлангыч, урта һәм югары һөнәр белеме бирү учреждениеләре хезмәткәрләренә – 35 мең сум күләмендә;

әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанслау тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетында Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла.»;

әлеге карар белән расланган Каюм Насыйри исемендәге премия турындагы нигезләмәне яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлә);

карарга түбәндәгеләрне өстәргә:

Каюм Насыйри исемендәге премия бирү комиссиясе турында нигезләмә (карарга теркәлә);

Каюм Насыйри исемендәге премия лауреаты дипломы бланкының үрнәге (карарга теркәлә);

Каюм Насыйри исемендәге премиягә бүләкләү кәгазьләре үрнәкләре (карарга теркәлә).

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Каюм Насыри исемендәге премия турында» 1995 ел, 19 июнь, 396 нчы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» 2005 ел, 4 март, 113 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Каюм Насыйри исемендәге премия турында» 1995 ел, 19 июнь, 396 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 ел, 30 декабрь, 1141 нче.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
1995 ел, 19 июнь, 396 нчы
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 27 февраль, 132 нче
карары редакциясендә)

## Каюм Насыйри исемендәге премия турындагы нигезләмә

### I. Гомуми нигезләмәләр

1. Каюм Насыйри исемендәге премия (алга таба – Премия) Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе субъектлары территориясендә урнашкан мәктәпкәчә, өстәмә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми, урта һөнәри һәм югары белем бирү оешмаларының педагогик коллективларына, хезмәткәрләренә бирелә.

2. Премия түбәндәге казанышлар өчен бирелә:

Татарстан Республикасында һәм Россия Федерациясе субъектларында милли мәгариф системасын камилләштерү һәм алга таба үстерүдә;

яшь буынны Татарстан Республикасы халыклары милли мәдәниятенең иң яхшы традицияләренә таянып укыту һәм тәрбияләү;

милли мәгариф оешмалары өчен укыту-методик комплектлар, туган тел һәм әдәбиятне, дәүләт теле буларак татар телен өйрәнү буенча дәреслекләр әзерләү;

милли мәгариф өлкәсендә фәнни хезмәтләр эшләү.

3. Премия Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы нигезендә Каюм Насыйри исемендәге премия бирү комиссиясе (алга таба – Комиссия) тәкъдиме белән бирелә.

4. Премияне алуга кандидатларның (алга таба – кандидатлар) шәхси һәм коллектив эшләре дә тәкъдим ителергә мөмкин.

Коллектив эш премиясе алуга тәкъдим ителгән очракта диплом, лауреат билгесе һәм таныклык лауреатларның һәркайсына тапшырыла, ә акчалата бүләк алар арасында тигез өлешләргә бүленә.

5. Кандидатның Премия алуга ике тапкырдан артмаган хокукы бар.

### II. Премия алуга кандидатуралар бирү тәртибе

6. Премия алуга кандидатларны тәкъдим итү мәгариф оешмасының педагогик советы яки мәгариф оешмасының башка коллегиаль органнары тарафыннан башкарыла.

7. Премияне алу өчен документлар Комиссия карап тикшерүенә кандидатлар тарафыннан ел саен 1 июньнән 1 июльгә кадәр тапшырыла.

8. Комиссия каравына түбәндәге документлар тапшырыла:

а) муниципаль районнарда һәм шәһәр округларында мәгариф өлкәсендә идарәне гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органнарының кандидатлар турында күзаллавы;

б) соңгы 5 елда мәгариф өлкәсендә кандидат эшчәнлеге нәтиҗәләрен характерлый торган документлар (белешмәләр, фикерләр, эксперт бәяләмәләре, рецензияләр яки башка документлар);

в) билгеләнгән формада бүләкләү кәгазе;

г) кандидатның эш урыныннан эш урыны буенча җитәкче имзасы һәм мәгариф оешмасы мөһере белән таныкланган белешмә.

9. Премия алуга материаллар кабул итү агымдагы елның 1 июлендә тәмамлана. Кергән материалларны карап тикшерү комиссия тарафыннан 1 августка кадәр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Каюм Насыйри исемендәге премия бирү комиссиясе турындагы нигезләмә нигезендә башкарыла.

10. Комиссиягә тапшырылган әлеге Нигезләмәнең 11 пунктында билгеләнгән критерийларга туры килми торган материаллар карап тикшерелми.

## III. Премия алуга кандидатларны сайлап алуның төп критерийлары

11. Премия алуга кандидатларны сайлап алуның түбәндәге критерийлары билгеләнә:

а) кандидатны премия алуга тәкъдим иткән елга кадәрге 5 ел эчендә педагогик эшчәнлекнең югары нәтиҗәлелеге һәм нәтиҗәлелеге;

б) соңгы 5 ел дәвамында муниципаль, төбәк һәм бөтенроссия һөнәри конкурсларда катнашу;

в) соңгы 5 ел дәвамында кандидатның укучылары һәм тәрбияләнүчеләре шәһәр, республика конкурсларында, фестивальләрдә, күргәзмәләрдә һәм башка чараларда катнашуы саны һәм нәтиҗәлелеге;

г) кандидатның үз педагогик тәҗрибәсен гомумиләштерү һәм таратуы (мастер-класслар, презентацияләр, «түгәрәк өстәлләр» дә, проектларда, педагогик укуларда катнашу, семинарлар, конференцияләр);

д) иҗади эзләнүләрдә, тәҗрибә-эксперименталь эштә катнашу;

е) укыту процессында кандидат тарафыннан заманча белем бирү технологияләрен куллану;

ж) халык педагогикасы өлкәсендә кандидатның эш тәҗрибәсен куллану һәм тарату, Татарстан Республикасы халыклары мәдәнияте традицияләрен, татар мәгърифәтчеләренең педагогик мирасын тәрбия процессында куллану;

з) кандидатның дәреслекләрне, уку әсбапларын, монографияләрне эшләүдә авторлыгы һәм (яки) автордашлыгы булу.

## IV. Премия бирү

12. Премия бирүгә сайлап алу җиңүчеләренә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Каюм Насыйри исемендәге премия турында» 1995 ел, 19 июнь, 396 нчы карарының 2 пунктында билгеләнгән күкрәк билгесе һәм акчалата премия тапшырыла.

13. Мәрхүм Премия лауреаты дипломы, мактаулы билгесе һәм акчалата премия законнар нигезендә аның варисына тапшырыла.

14. Премия лауреаты хезмәт кенәгәсенә, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының премия бирү турындагы боерыгының номеры һәм датасын күрсәтеп, аны бирү турында язма кертелә.

15. Премия бирү турында Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы «Мәгариф»журналында басылып чыгарга тиеш.

16. Премия бирү буенча карап тикшерелгән материаллар Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы архивына 5 елга саклауга тапшырыла.

17. Әгәр Премиягә дәгъва кылучылар арасында аны бирү критерийларына туры килмәсә, Премия бирелми.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
1995 ел, 19 июнь, 396 нчы
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 27 февраль, 132 нче
карары редакциясендә)

Каюм Насыйри исемендәге премия бирү комиссиясе турында нигезләмә

1. Каюм Насыйри исемендәге премияне бирү комиссиясе (алга таба – Комиссия) Каюм Насыйри исемендәге премиягә кандидатлар эшенә экспертиза оештыру һәм үткәрү, иң яхшы кандидатларны сайлап алу һәм Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына Премия бирү турында тәкъдимнәр кертү максатыннан оештырыла.

2. Комиссия 11 әгъзадан тора, алар арасына рәис, аның урынбасары һәм секретарь керә.

3. Комиссиянең шәхси составы Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы белән раслана. Комиссия рәисе – Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министры.

4. Комиссия составына Татарстан Республикасы дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, җәмәгатьчелек, белем бирү, фәнни һәм башка оешмалар вәкилләре кертелә (килештерү буенча).

Комиссиянең барлык әгъзалары үз эшчәнлекләрен түләүсез нигездә башкара.

5. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары, Каюм Насыйри исемендәге премия турындагы нигезләмә, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

6. Комиссиянең төп бурычы – премия алуга кандидатлар документларын карап тикшерү, иң яхшы кандидатларны сайлап алу һәм Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына премия бирү турында тәкъдимнәр кертү.

7. Комиссия Функцияләре:

премия алуга кандидатлар документларын карап тикшерү;

премия алуга кандидатларның документларына экспертиза үткәрү һәм эксперт бәяләмәсе бирү;

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына беркетмәне рәсмиләштереп, премия бирү турында коллегиаль карар кабул итү.

8. Комиссия әгъзалары түбәндәгеләргә хокуклы:

законда билгеләнгән тәртиптә дәүләт органнарыннан, муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарыннан, шулай ук фәнни һәм башка оешмалардан Комиссия карамагына кертелгән мәсьәләләр буенча материалларны

һәм мәгълүматны соратып алырга;

билгеләнгән тәртиптә Комиссиядә эшләүгә Татарстан Республикасы дәүләт органнары, муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары, мәгариф, фәнни һәм башка оешмалар вәкилләрен җәлеп итәргә.

9. Комиссиянең бурычлары:

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан фәнни һәм мәгариф оешмалары белән Премия бирү мәсьәләләре буенча хезмәттәшлекне оештыру;

эксперт нәтиҗәләрен коллегиаль карап тикшерү һәм Премия бирү турында Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына тәкъдимнәр кертү.

10. Комиссия утырышы елга бер тапкыр үткәрелә, әгәр анда Комиссия әгъзаларының гомуми санынннан кимендә өчтән икесе катнашса, ул тулы хокуклы санала.

11. Комиссия эшчәнлеге белән җитәкчелек итү Комиссия рәисе, ә ул булмаганда Комиссия рәисе урынбасары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

12. Комиссия секретаре Комиссия әгъзалары арасыннан комиссия рәисе тарафыннан билгеләнә.

13. Комиссия секретаре Комиссия утырышларын әзерләү һәм үткәрү, шул исәптән Комиссия каравына тәкъдим ителә торган Премия алуга кандидатлар документларын карап тикшерү буенча оештыру һәм техник эшне башкара, шулай ук Комиссия утырышы беркетмәсен әзерли.

14. Комиссиянең Премия бирү турындагы карары утырышта катнашкан Комиссия әгъзаларының яртысыннан артыгы тавыш биргән очракта кабул ителгән дип санала. Тавышлар тигез булганда Комиссия утырышында рәислек итүче тавышы хәлиткеч булып тора.

15. Комиссия карары тавыш бирү нәтиҗәләре буенча беркетмә белән рәсмиләштерелә, ул Комиссия секретаре һәм тавыш бирүдә катнашкан барлык әгъзалары тарафыннан имзалана, Комиссия утырышында рәислек итүче тарафыннан раслана.

16. Премия бирү буенча Комиссия утырышы нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрының премия бирү турында боерыгы чыгарыла.

17. Комиссия эшчәнлеген матди-техник һәм финанс ягыннан тәэмин итүне Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы башкара.

___

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
1995 ел, 19 июнь, 396 нчы
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 27 февраль, 132 нче
карары редакциясендә)

Каюм Насыйри исемендәге премия лауреаты дипломы бланкының үрнәге

| Левая сторона | Правая сторона |
|---|---|
| на татарском языке | на русском языке |
| ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ<br><br>Каюм Насыйри исемендәге<br>премия лауреаты<br><br>**ДИПЛОМЫ**<br><br>*эш урыны, вазыйфасы*<br>*фамилиясе, исеме, атасының исеме*<br>милли мәгарифне үстерүдәге<br>казанышлары өчен<br><br>Татарстан Республикасы<br>Премьер-министры урынбасары –<br>Татарстан Республикасы<br>мәгариф һәм фән министры *Ф.И.Ат.ис.*<br><br>Казан шәһәре<br>«__» ________ 20__ ел<br>М.У.<br>Серия | МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН<br><br>**ДИПЛОМ**<br><br>лауреата премии имени<br>Каюма Насыри<br><br>*место работы, должность*<br>*Ф.И.О.*<br>за заслуги в развитии<br>национального образования<br><br>Заместитель Премьер-министра<br>Республики Татарстан –<br>министр образования и науки<br>Республики Татарстан *Ф.И.О.*<br><br>город Казань<br>«__» _______ 20__ года<br>М.П.<br>Серия |

_______________________________________